| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2024 г.Казань № 505-47/тко-2024

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

Баулы шәһәренең «Төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе» муниципаль казна предприятиесе өчен каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә хезмәт күрсәтү буенча җайга салынулы эшчәнлек төрен гамәлгә ашыруны туктатуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 13.12.2024 ел, №32-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе» муниципаль казна предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2021 – 2025 елларга чик дәрәҗә тарифлар билгеләү хакында» 17.12.2020 ел, №560-20/тко-2020;

«Төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе» муниципаль казна предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 ел, №560-20/тко-2020 карары белән расланган озак сроклы чик тарифларны 2023 ел өчен үзгәртү хакында» 15.11.2022 ел, №429-18/тко-2022;

«Төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе» муниципаль казна предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 ел, №560-20/тко-2020 карары белән расланган озак сроклы чик тарифларны 2024 ел өчен үзгәртү хакында» 08.12.2023 ел, №485-23/тко-2023.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев